**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 3 июнь | № 400

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турында» 2010 ел, 21 май, 398 нче карары белән расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын бирү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантларын бирү эшен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турында» 2010 ел, 21 май, 398 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 23 февраль, 157 нче; 2013 ел, 11 май, 319 нчы; 2013 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 25 сентябрь, 673 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан

Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын бирү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләрне кертергә:

Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү яки фәнни оешмаларына стажировкага яки магистратурада укуга җибәрелә торган «Яшь галимнәр» категориясе буенча 35 яшькә кадәр (35 яшьне кертеп) һәм «Ике диплом» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләр арасыннан конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

Илдар Ирек улы Гыйлметдинов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча)»;

ярдәмче комиссия составыннан Айрат Радин улы Шәфигуллинны чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына Эльмира Әмир кызы Зарипованы – Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрын кертергә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәр белеме бирү оешмалары арасыннан, югары һөнәр белеме бирү оешмалары һәм фәнни оешмалар укытучылары һәм фәнни хезмәткәрләре арасыннан «Югары һөнәр белеме бирү оешмалары» категориясе һәм «Укытучылар һәм фәнни хезмәткәрләр» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

ярдәмче комиссия составыннан Шамил Мәхмүт улы Вәлитовны чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына Наилә Гомәр кызы Баһаветдинованы – Казан (Идел буе) федераль университетының Идарә, икътисад һәм финанслар институты директорын кертергә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының инглиз теле мөгаллимнәре, һөнәр белеме бирү оешмаларының инглиз теле укытучылары арасыннан грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

Аида Гомәр кызы Садыйкова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Л.Н.Толстой исемендәге рус һәм чит ил филологиясе бүлегенең контрастив лингвистика һәм лингводидактика кафедрасы мөдире, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе (килешү буенча)»;

ярдәмче комиссия составыннан Әсәдулла Хәбибулла улы Садыйковны, Наталья Анатольевна Чайканы чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Илдар Гыйләҗетдин улы Шәмсетдиновны – «В.П.Лушников исемендәге Казан нефть химиясе көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорын (килешү буенча);

Альбина Ильяс кызы Әсәдуллинаны – Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 нче лицей муниципаль бюджет гомуми белем бирү

учреждениесе директорының уку-укыту эшләре буенча урынбасарын (килешү буенча);

Икътисадның реаль секторындагы предприятиеләр белгечләре, аккредитацияләнгән белем бирү оешмаларының югары технологияләр өлкәсендә инновация проектларын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп ителүче магистрантлары, аспирантлары, штат укытучылары һәм фәнни хезмәткәрләр арасыннан «Проект төркемнәре» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

ярдәмче комиссия составыннан Артем Алексеевич Здуновны чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына Булат Зөфәр улы Хаҗиәхмәтовны – Татарстан Республикасының икътисад министры урынбасарын, ярдәмче комиссия рәисен кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\400.doc